КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 8 октябрь г.Казань № 911

Кукмара муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Кукмара муниципаль районының «Сосенка» җәйге балаларны савыктыру лагеры» муниципаль бюджет учреждениесенең Кукмара муниципаль районында урнашкан, Кукмара муниципаль районы милкендә булган 3,5055 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:23:050102:39 кадастр саны белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрдә күрсәтелгән чикләрдә туристлык хезмәте күрсәтү объектын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин